Духовно-просветительская газета

Индекс 52381

## Котлыйбыз!

Тарихыбыз кискен борылыш ясаганда милләтне, гореф-гадәтләрне һәм динне үстерү өчен төрле мөмкинлекләр туды. Диннән шактый читләштерелгән, милли хисләре имгәнгән халыкка рухи көч, киләчәккә ышаныч биреп, иияртеп китүчеләр дә табылды. Катлаулы заманнарда алар җәмгыятебез алдында зур-зур максатлар куеп, шуларны тормышка ашыруга зур көч куйдылар. Быел изге Шаабан аенда танылган милли хәрәкәт эшлеклеләребезнең юбилейлары көтелә.

**Болар - Җәмил Әхмәдулла улы ВӘЛИУЛЛИН**
**һәм Шамил Сәлиметдин улы БАҺАУТДИН**

### Шамил Сәлиметдин улы Баһаутдинга — 70 яшь!



**Шамил әфәнде!**

Самара өлкәсе татарлары башкарган күптөрле зур проектларның һәрберсендә Сезнең катнашыгыз бар.

Бәйрәмнәребезне оештыруда, милли мәдәният һәм мәгърифәт өлкәсендәге казанышларның һәрберсендә Сезнең зур өлешегез бар.

Сез үз гомерегездә милләтебез киләчәгеннән кайгыртып яшисез. Халкыбызның милли үзаңын, тәрбиялелеген, динлелеген үстерүгә дә күп көч куясыз.

Сез - үрнәкле чын ир, таләпчән гаилә башлыгы, акыллы әти һәм ягымлы бабай.

Сез - оста журналист та, оста җитәкче дә, көчле оратор да. Халыкны үзегезгә ияртә беләсез.

Киләчәктә дә безгә, булган мөмкинлекләребезне берләштереп, халкыбызга, динебезгә бергә уңышлы хезмәт итәргә насыйп булсын иде.

Алдагы көннәребездә әле зур эшләр башкарасыбыз, дингә, милләткә ышанычлы хезмәт күрсәтәсебез бар.

Аллаһы Тәгаләдән Сезгә исәнлек, озын гомер, иҗади уңышлар, зиһен сафлыгы, хисләр байлыгы һәм бәхетле тормыш телибез.

***Самара өлкәсе Диния нәзарәте,***
***Самара Җәмигъ мәчете,***
***татар җәмгыятьләре,***
***Самара мөселманнары.***

### Җәмил Әхмәдулла улы Вәлиуллинга - 65 яшь!



**Хөрмәтле дин кардәшебез!**

Инде чирек гасыр буена без һәрвакыт Сезнең ярдәмегезне тоеп, күптөрле кыенлыкларны җиңеп, зур-зур планнарны тормышка ашырып яшибез.

Туры сүзле, кыю фикерле буларак, Сез күп вакытта катлаулы мәсьәләләрне хәл иткәндә актив катнашасыз.

Киләчәктә дә бердәм, фикердәш булып, зур эшләр башкарасыбыз бар. Киләчәктә дә Сез безнең ышанычлы киңәшчебез булырсыз, дип ышанабыз.

Аллаһы Тәгаләдән исәнлек, гаилә бәхете, балалар, оныклар игелеген күреп, озын гомер кичерүегезне телибез.

***Самара өлкәсе Диния нәзарәте,***
***Самара Җәмигъ мәчете,***
***Самара мөселманнары.***

**Самара татар милли-мәдәни тормышында үз эзен калдырган шәхес буларак, Җәмил әфәнде безләргә газиз.**

Зур хезмәт коллективын җитәкләгән ир буларак, аның эшләү ысулы сокланып искә алырлык.

Җитәкчеләр белән элемтәгә керә белүчеләр бармак белән генә санарлык. Шул сирәкләрнең берсе - Җәмил Вәлиуллин.

Уңган, булдыклы, тормышның мәгезеннән борып алып баручы. Ярдәмчел, туры сүзле, каты әйтә, берлекле әйтә, ләкин дә гаделлеге белән истә кала.

Җәмил әфәнде, йөрәк түребездән кайнап чыккан сәламнәребезне кабул итегез. Ходай Тәгалә үзегезгә сихәтлек һәм озын гомер бирсен. Киләчәктә дә куандырып һәм куаныч яшәгез.

**(tatarlarsamara.org)**

### Объявление

Самарской Исторической мечети (ул. А. Толстого, 61) требуются дежурные - 2 человека.

**Т.: 340-74-66.**

**Администрация.**

## Табиб мөнбәре

# Файдалы киңәшләр

### Борын авырулары

Урысчасы — насморк, грекча — «борын» сүзеннән. Томау борын куышлыгының лайлалы сүрүе ялкынсынудан төшә. Ул көчле һәм даими була. Көчлесе, гадәттә, борын эче кибеп әчетүдән башлана. Кеше төчкерә, башы авырта, хәлсезләнә, температурасы күбесенчә күтәрелми. Аннары борыннан ага башлый. Борын сүрүенең ялкынсынуы аркасында борын белән сулау кыенлаша, ис сизү кими, күздән яшь ага, тавыш үзгәрә, кайчакта колак тыгыла, ишетү начарлана. Борын тишеге янындагы тире шешә, вакыт-вакыт ярылып та китә. Көчле томау кайчагында борынның өстәмә чокырлары шешүдән катлаулана. Көчле томау берничә көнгә яки 2-3 атнага сузыла. Көчле томауны китереп чыгарган сәбәпләр: температураның кискен үзгәрүе, үтәли җил.

Даими томау вакытында борыннан гел агып тора, әледән-әле борын белән сулау кыенлаша.

Томауның барлык төрләрен күптөрле юллар белән дәвалыйлар.

***Бу чиргә каршы халкыбыз кулланган чаралар***

**Башланган гына чагында:**

*Үкчәгә горчичник ябыштырып, фланель белән бәйләп куярга кирәк. Өстеннән йон оекбаш киеп, 1-2 сәгать тотарга.*

*Горчичникларны алгач, бернигадәр вакыт ишекле-түрле кызу-кызу йөрергә. Моны кичен, йокларга ятар алдыннан эшләү әйбәт. Томау иртәнгә кадәр юкка чыгачак.*

*Грипп белән бәйле булмаса, ярты стакан суга 5 тамчы йод тамызып эчү дә файдалы.*

*Бер тырнак сарымсак ашарга.*

**Азган формасын дәвалау өчен:**

*Һәр ярты сәгать саен нашатырь спиртын әле бер, әле икенче борын тишеге янына куеп иснәргә.*

*Борынга 3-5 тамчы ментол мае тамызырга, шул ук вакытта аны маңгайга, чигәләргә һәм борынга сөртергә. Ментол маен яртылаш камфара мае белән дә катнаштырырга ярый.*

*Борынның һәр тишегенә 5-6 тамчы яңа гына сыгып чыгарган чөгендер согын тамызырга яки, шул суга манып, борын тишегенә мамык тыгарга. Чөгендер суына бал кушарга да ярый.*

**Томау белән еш авырган, даими булганыннан интеккән кешеләр өчен:**

*Һәр көнне алмаш-тилмәш әле бер, әле икенче борын тишегенә, суырган су авызга үтеп чыгарлык итеп, тозлы су суырырга (1 стакан суга 1 чәй кашыгы аш яки диңгез тозы алына).*

***Фәния ХУҖАХМӘТ.***
***(«Һәр авыруга дәва бар» китабыннан)***

# Күз тию

Күз тию дигән нәрсә бар, һәм ул кешенең динле яки динсез булуына, нинди дин тотуына бәйле түгел. Аның төп сәбәбе — көнчелек. Күз тидерүчеләр ике төрле була. Берәүләр үзләренең мондый «сәләткә» ия булуын белми, ә икенчеләре белә торып, моннан файдалана. «Синең чәчләрең нинди матур, ә синең энергияң ташып тора», — дияргә мөмкин ул. Нәтиҗәдә, тегеләрнең чәче коела, көче китә башлый...

«Күз тидерә ала торган һәркем — көнчел кеше. Әмма көнләшә торган һәркем күз тидерү сәләтенә ия түгел», диеләр. Кеше үз-үзенә, ана кеше үз баласына күз тидерә ала. һәркемнең эчендә шайтан утыра. Көнләшү сездә утырган шайтан аркылы бара. Аналар еш кына үз балаларына үзләре күз тидерәләр, балалары елый башлый. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк соң? Тынычландыру өчен баланы сул тезегезгә утыртасыз да уң колагына Коръән сүрәләре — «Колһу Аллаһы», «Фәләкъ», «Нәс»не укыйсыз. Су да өшкереп эчертә аласыз.

Күз тию — тискәре энергия. Ул башта кешенең күкрәгенә бәрә. Кешегә сулыш алу авырлаша, һава җитми башлый. Кеше табибка йөгерә, тикшерене, тик алар берни тапмый. Ә авыру иңбашларына, муенга менә. Кеше тоз утыру галәмәте дип уйлый, тиз арый. Тискәре энергия бер урында гына тормый — башка менеп җитә. Кешедә кызып китүчәнлек, баш авырту, депрессия башлана, йокысы кача, яшисе килми. Авыру исә организм буйлап аска төшә башлый, хатын-кыз авырулары китереп чыгара, аннары буыннарга күчә. Авырту шул рәвешле бөтен тән буйлап хәрәкәт итә. Бу дару төймәләре белән генә чыга торган нәрсә түгел. Депрессиягә каршы дарулар да авыртуны вакытлыча гына баса.

Кеше тәннән һәм җаннан тора, дибез. Тәнне ул кайгырта: вакытында ашый, эчә, йоклый, юына. Ә җан турында онытa — намаз укымый, зекер әйтми, ураза тотмый. Кешенең физик иммунитеты яхшы, ә җан иммунитеты начар, ягъни иманы зәгыйфь. Күз тимәсен дисәң, җанны кайгыртырга кирәк.

Бик күп чирләрнең башы — күз тиюдә һәм бозым керүдән. Минем яныма операциягә ризалашкан кешеләрнең дә килгәне бар. Укый башлыйсың, ә анда — сихер. Керми тор, дим. Бер атна дәвамында мин биргән таләпләрне үтәгәннән соң, шеш юкка чыга. Табиблар да шаккатa. Күз тиюдән, сихердән операция ясатып кына да котылып булмый. Кешенең эчендә калган негатив энергия организмның башка зәгыйфь урынын эзләп табачак. Аны бары тик Коръән белән генә дәвалап була. Авыру кешенең үзенә дә Коръән укырга кирәк.

**Ильяс хәзрәт МӘХМҮТ.**

***Уважаемые читатели!***
***В газете упоминаются имена Всевышнего и Его Пророка, публикуются аяты из Корана, высказывания Пророка и молитвы. Поэтому просим Вас относиться к газете уважительно, не использовать ее в недостойных целях.***
***Точка зрения авторов может не совпадать с мнением редакции.***

**УЧРЕДИТЕЛИ:** Региональное Духовное управление мусульман Самарской области и местная мусульманская религиозная организация Самарская Соборная мечеть.
**АДРЕС РЕДАКЦИИ И ИЗДАТЕЛЯ:** 443081, г. Самара, ул. Стара Загора, 54. Соборная мечеть. Телефон: 932-58-67. Электронный адрес: islam-nur@bk.ru

**Редактор** - Фарид ШИРИЯЗДАНОВ.
**Корреспондент** - Али СУЛЕЙМАНОВ.
**Ответственные за выпуск газеты:**
**по организационно-финансовым вопросам** - Джавдят ШАРАПОВ,
**по духовно-просветительской части** - Наиль СУЛЕЙМАНОВ.
**Набор и верстка** - Рамиль НУРЕТДИНОВ.
**Корректор** - Миляуша ГАЗИМОВА.

**Время подписания к печати:**
***по установленному графику - 2 июля 9.00,***
***фактически - 2 июля 9.00.***

**Отпечатано в ОАО «Типография «Солдат Отечества»**
**Адрес: г. Самара, ул. Авроры, 112 Б.**
**Заказ Тираж 2000.**
***Цена свободная.***
Рег. свидетельство ПИ № ТУ63-00111